МИНИСТЕРСТВ ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МОНОСЭБОТЛЭРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

07.04.2023 Казан ш. № 972-р

Газ бүлү челтәренең (газүткәргеч) саклык чикләрен үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Яшел Үзән муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәрләрен (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен раслау турында” 25.09.2014 № 1985-р карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, “Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында” 2015 елның 15 июлендәге № 218-ФЗ Федераль Законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында” 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасы техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ тарафыннан әзерләнгән документациягә туры китереп, «Фонд пространственных данных Республики Татарстан» ДБУның хатын (31.03.2023 № 01А-04/716) истә тотып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Яшел Үзән муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәрләрен (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен раслау турында” 25.09.2014 № 1985-р карары (алга таба - № 1985-р Карар) белән урнаштырылган 1070 км. озынлыктагы, инвентарь номеры 10283, реестр номеры 16:20-6.49 булган бүлү газүткәргеченең саклау зонасын туктатырга.

2. Газүткәргечен күчерү сәбәпле Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Яңа Тура авыл җирлеге территориясендә гомуми мәйданы (25522 ± 56) кв.м.лы территорияне тәшкил иткән «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милкендә булган газ бүлү челтәре объектының саклау зонасын (инвентарь номеры 10283 булган газ бүлү газүткәргеченең саклау зонасы) территорияне файдалануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасы, «Татарстан Республикасы техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ тарафыннан әзерләнгән җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп урнаштырырга.

3. Инвентарь номеры 10283 булган газ бүлү челтәренең эксплуатация срогында өлешчә яки тулысынча газүткәргечләрнең саклау зонасына туры килгән әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

4. Территорияне файдалануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасынданы белешмәләргә, «Татарстан Республикасы техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ тарафыннан әзерләнгән җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп, № 1985-р Карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Яшел Үзән районы территориясендә әлеге карарның 1 нче кушымтасындагы инвентарь номерлы, «Граница» кадастр үзәге» ҖЧҖ, «Татарстан Республикасы техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ тарафыннан башкарылган җир өсте һәм җир асты объектларының саклау зонасы картасында (планда) булган белешмәләр нигезендә Яшел Үзән районы буенча ЭПУ «Зеленодольскгаз» газ бүлү челтәрләре (газүткәргечләр) объектларының саклау зонасын билгеләргә»;

1 нче кушымтада:

инвентарь номеры 10283 булган газүткәргечenә (Осиново авыл җирлеге, Яңа Тура авылы) туры килгән юлларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Газ бүлү газүткәргеченең инв. № (ОС) | Адрес | Хокук төре | Составына саклау зонасында урнашкан җир кишәрлеге кергән бердәм җир куллану кадастр номеры | Саклау зонасында урнашкан җир кишәрлегенең кадастр номеры | Җир категориясе | Мәйданы | Саклау зонасында урнашкан җир кишәрлегенең милекиясе | Рөхсәт ителгән куллану төре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 10283 | Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яңа Тура авылы, Луговая ур. | Милек | | 16:20:080202:843 | Торак пунктлар җирләре | 35.00 | Гатиатуллин Артур Асхатович | Хосусый ярдәмче хуҗалык тоту өчен |
| 10283 | Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яңа Тура авылы, Луговая ур. | Милек | | 16:20:080202:842 | Торак пунктлар җирләре | 0.00 | | Хосусый ярдәмче хуҗалык тоту өчен |
| 10283 | Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яңа Тура авылы | Милек | | 16:20:080202:792 | Торак пунктлар җирләре | 0.00 | | Трубоүткәргеч транспорт (75) |
| 10283 | Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яңа Тура авылы | Милек | | 16:20:080202:361 | Торак пунктлар җирләре | 0.00 | | Газ белән тәэмин итү инженерлык объекты өчен |
| 10283 | Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Яңа Тура авылы | Милек | | 16:20:080202:155 | Торак пунктлар җирләре | 87.00 | Медведева Фарида Гарифовна | Хосусый ярдәмче хуҗалык тоту өчен |

5. Әлеге карарның үтәлеген контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**